Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Башкарма комитеты

КАРАР

08 апрель 2026 ел № 3

Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Иске Михайловка авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Башкарма комитетының карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2015 елның 20 ноябрендәге 9 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында»;

- 2020 елның 14 маендагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 9 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Михайловка авыл башкарма комитеты җитәкчесе А.Ю.Зарубин